КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 июль г.Казань № 851

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы; 2022 ел, 7 март, 202 нче; 2022 ел, 17 март, 244 нче; 2022 ел, 29 апрель, 402 нче; 2022 ел, 22 сентябрь, 1029 нчы; 2022 ел, 11 ноябрь, 1196 нчы; 2023 ел, 6 март, 214 нче; 2023 ел, 21 март, 306 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 2 888 мең сумлык айлык фонды белән 159 берәмлек итеп билгеләргә, шулардан:

40 берәмлеге – вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 883,9 мең сумлык айлык фонды белән үзәк аппараты хезмәткәрләре, шулардан:

18 берәмлеге – федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслана торган вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 327,9 мең сумлык айлык фонды белән;

22 берәмлеге – Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 556,0 мең сумлык айлык фонды белән;

119 берәмлеге – вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 2 004,1 мең сумлык айлык фонды белән территориаль бүлекчәләр хезмәткәрләре, шулардан:

18 берәмлеге – федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслана торган вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 379,0 мең сумлык айлык фонды белән;

101 берәмлеге – Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 1 625,1 мең сумлык айлык фонды белән.»;

4.2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 4.2.1.1 пунктча өстәргә:

«4.2.1.1. Татарстан Республикасы Рәисенең төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясенең саклау зонасын билгеләү, үзгәртү яки гамәлдә булуын туктату турындагы акт проектын әзерли һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;»;

4.2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.2. Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрен һәм аларның саклау зоналарын билгеләү эшләрен оештыра;»;

5.1 пунктның 5.1.2 пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6.4 пунктның 6.4.4 пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар, әлеге карарның 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган 1 пунктындагы өченче – унынчы абзацларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин